**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

| **ПРИКАЗ** | Казан ш. | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| 29.08.2022 | | 748-п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «Космос» шифаханә-профилакторие территориясендә №16, №17 су алу скважиналарының санитар саклык зоналарын билгеләү турында» 2022 елның 16 мартындагы 196-п номерлы боерыгына 1 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «Космос» шифаханә-профилакторие территориясендә №16, №17 су алу скважиналарының санитар саклык зоналарын билгеләү турында» 2022 елның 16 мартындагы 196-п номерлы боерыгына 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8-13 абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Санитар саклык зонасының I поясы.

Санитар саклык зонасының беренче поясы чиге №17 скважинадан төньяктан – 16 м, көнбатыштан – 24 м, көньяктан – 40 м; №16 скважинадан төньяктан – 21 м, көнчыгыштан – 13 м, көньяктан – 28 м, ягъни булган коймалар чикләрендә билгеләнә.

Санитар саклык зонасының II поясы

Санитар саклык зонасының икенче поясы чиге №16 скважинадан агым буенча өскә таба – 26 м, агым буенча аска таба – 17 м, киңлеге – 21 м; №17 скважинадан агым буенча аска таба – 13 м, агым буенча өскә таба – 18 м, киңлеге 16 м аралыкта билгеләнә.

Санитар саклык зонасының III поясы

№16, №17 скважиналар өчен санитар саклык зонасының өченче поясы чиге агым буенча аска таба – 33 м, агым буенча өскә таба – 415 м, киңлеге – 227 м.».

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары И.И.Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков